ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Җир асты байлыклары турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның өченче өлешендә “радиоактив, агулы һәм бүтән төрле куркыныч калдыкларны” сүзләрен “радиоактив калдыкларны, I – V класслы хәвефлелектәге калдыкларны” сүзләренә, “агулы һәм бүтән төрле куркыныч калдыклардан” сүзләрен “I – V класслы хәвефлелектәге калдыклардан” сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның икенче өлешендә “кишәрлегендә файдалы казылмаларны” сүзләреннән соң “чит ил инвесторлары контрольлегендәге юридик зат яисә чит ил инвесторы тарафыннан” сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын чыгару өчен яисә җир асты суларын табу һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү турында.”;

4) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“29 статья. **Җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендага алучыларның җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан үз ихтыяҗлары өчен файдалану хокуклары**

Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендага алучылар үз ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, шартлату эшләрен кулланмыйча, әлеге җир кишәрлекләре чикләрендә табылган һәм дәүләт балансында исәпләнмәгән гомумтаралган файдалы казылмалардан файдаланырга, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булмаган һәм үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булган җир асты сулыклары өстендә урнашкан җир асты сулыкларыннан тәүлегенә 100 куб метрдан артык булмаган күләмдә җир асты суларыннан файдаланырга, шулай ук биш метр тирәнлеккә кадәр җир асты корылмалары төзергә хокуклы.

Гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан үз ихтыяҗлары өчен файдалану дигәндә әлеге статья максатларында җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендага алучыларның алардан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдалануы аңлашыла.

Җир кишәрлегендә табылган һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары читләштерелми яисә бер заттан икенчесенә күчә алмый.”;

5) III[1] бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**III[1] бүлек. ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ҖИР АСТЫ БАЙЛЫКЛАРЫ КИШӘРЛЕКЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ ХОКУКЫН БИРҮ**

35[1] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү**

Гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы, әлеге статьяның икенче өлешендәге өченче, дүртенче, алтынчы абзацларында каралган очраклардан тыш, аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы аукцион үткәрмичә түбәндәге максатлар өчен бирелә:

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ

әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану;

ачык ятмадагы гомумталралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, әлеге ятманың гомумталралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану;

гомумталралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү;

җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, җир асты суларын чыгару яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### $35^2$ статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү тәртибе**

Әлеге Законның $35^1$ статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен аукционда катнашуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) аукционда катнашу өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвештә гариза бирә, шулай ук түбәндәге документларны тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтәне;

салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә куелуы турында таныклыкның күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычы булу яисә булмау турында салым органнарыннан белешмәне;

мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителәчәк подрядчикларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре (алар булса) күчермәләрен;

соңгы хисап датасына мөрәҗәгать итүченең бухгалтерлык балансы күчермәсен, аңа кабул ителүе хакында салым органы билгесе куелган булырга тиеш;

гариза биргән датага кадәр узган ай дәвамында мөрәҗәгать итүченең счетлары буенча акчалар йөреше турында банк учреждениеләреннән белешмәләрне;

заем яисә кредит шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

подряд шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

кулланыла торган технологияләр һәм аларның тасвирламалары турында белешмәне һәм мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителәчәк подрядчикның бораулау, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралары булуын раслый торган исемлеген;

мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителәчәк подрядчикларның штат расписаниесе күчермәсен;

эшләрне башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләрен.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү турында, аукцион комиссиясенең составы һәм эш тәртибе турында карарлар кабул итү һәм җир асты байлыкларының һәр кишәрлегенә яисә җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата мондый аукционнарны үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

35$^{3}$ статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү тәртибе**

Әлеге Законның 35$^{1}$ статьясындагы икенче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) әлеге хокукны алу өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвештә гариза бирә.

Мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карар кабул итү өчен әлеге Законның 35$^{4}$ – 35$^{8}$ статьяларында каралган документлар кирәк. Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы, гариза һәм кирәкле барлык документлар алынган көннән алып 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында яисә мондый хокукны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көне эчендә бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Бу чакта җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә мөрәҗәгать итүчегә, баш тартуның сәбәбләре күрсәтелеп, язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).

**35[4] статья. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

җир асты корылмасын төзүнең расланган проектыннан төзелеш объектының күләмнәре турында белешмәләр булган өземтә.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – бишенче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

**35[5] статья. Ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару максатларында файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә, җирле

әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару максатларында файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын раслау беркетмәсенең күчермәсе;

мөрәҗәгать итүче гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш (“елга-диңгез”) йөзү судноларын “ГЛОНАСС” яисә “ГЛОНАСС/GPS” спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә “ГЛОНАСС+112” бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланма урнаштыру акты күчермәсе (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән суднолардан файдаланганда);

мөрәҗәгать итүченең файдалануга бирелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турында таныклык күчермәсе.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге җиденче абзацында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^6$ статья. **Файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары

кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмаларның расланган запаслары беркетмәсе күчермәсе;

мөрәҗәгать итүче гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш (“елга-диңгез”) йөзү судноларын “ГЛОНАСС” яисә “ГЛОНАСС/GPS” спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә “ГЛОНАСС+112” бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланма урнаштыру акты күчермәсе (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән суднолардан файдаланганда);

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^7$ статья. **Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне

саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – дүртенче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^8$ статья. **Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, шулай ук җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

мөрәҗәгать итүченең файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартлары буенча тәкъдимнәре, аларга эшләрнең төрләрен, күләмнәрен, үткәрү вакытын, геологик өйрәнүнең, шул исәптән файдалы казылмалар запасларын арттыру буенча көтелгән нәтиҗәләрен күрсәтеп, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү буенча тәкъдимнәр керә;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт контракты күчермәсе (күрсәтелгән эшләр дәүләт контракты нигезендә башкарылган очракта).

Җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче – унынчы абзацларында каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары

кишәрлегендә җир асты сулары запасларын раслау беркетмәсе күчермәсе;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында әлеге статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән белешмәләр булган мәгълүмат;

су җыю скважинасы паспорты күчермәсе;

җир асты суларын чыгаруның күрсәтелгән күләмен исәпләү һәм нигезләү;

су объектының санитария кагыйдәләренә һәм су объектыннан халык сәламәтлеге өчен имин файдалану шартларына туры килүе турында санитария-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе.

Файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында әлеге статьяның икенче өлешендәге бишенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматта түбәндәгеләр булырга тиеш:

җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик төзелеше турында белешмәләр, шул исәптән файдаланыла торган җир асты сулыгы хакында белешмәләр;

җир асты суларына ихтыяҗны һәм җир асты суларын файдалануның максатчан билгеләнешен дәлилләү;

су әзерләү системасын куллану турында белешмәләр (булган очракта);

җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан су җыю корылмасы схемасы, скважиналарның географик координаталары;

җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның конструкцияләре һәм билгеләнеше турында белешмәләр;

су җыю корылмасыннан файдалану режимына характеристика;

чыгарыла торган җир асты суларының күләмен һәм сыйфатын исәпкә алуның һәм тикшерүнең булган чаралары турында белешмәләр;

җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты суларын күрсәтелгән ихтыяҗ күләмендә чыгару мөмкинлеген дәлилләү.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унынчы абзацларында, әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – дүртенче абзацларында, икенче өлешендәге икенче – җиденче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында, әлеге статьяның беренче өлешендәге бишенче абзацында, икенче өлешендәге сигезенче абзацында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^9$ статья. **Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту**

Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту түбәндәге очракларда булырга мөмкин:

гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән булса, шул исәптән аның

эчтәлеге аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә;

мөрәҗәгать итүче махсус рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырган булса;

мөрәҗәгать итүче эшләрне нәтиҗәле һәм имин алып бару өчен үзендә квалификацияле белгечләрнең, кирәкле финанс һәм техник чараларның булуы яисә булачагы турында дәлилләрне тапшырмаган һәм тапшыра алмый торган булса;

әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы законнар таләпләре үтәлми торган булса.";

6) 73 статьяда:

а) тугызынчы абзацта "радиоактив, зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын" сүзләрен "I – V класслы хәвефлелектәге калдыкларны" сүзләренә алмаштырырга, "(шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләре булганнарын да)" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) уникенче абзацта "яисә сәнәгать сулары белән тәэмин итү максатлары өчен кулланыла торган йә эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганаклары буларак резервлана торган" сүзләрен "(алга таба – эчәр сулар белән тәэмин итү) яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү яисә эчәр сулар белән тәэмин итү чыганаклары буларак резервлана торган" сүзләренә алмаштырырга;

7) 84 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"84 статья. **Файдалы казылмалар запасларына дәүләт экспертизасы**

Файдалануга бирелә торган җир асты байлыкларыннан рациональ комплекслы файдалану өчен шартлар тудыру, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүне, җир асты байлыклары кишәрлекләренең чикләрен билгеләү максатларында, разведкаланган ятмаларның файдалы казылмалар запаслары дәүләт экспертизасы узарга тиеш, моңа эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендәге җир асты сулары запаслары керми.

Җир асты байлыкларын файдалы казылмалар чыгару өчен бирү аларның запасларына дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә, моңа эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен бирү керми.

Разведкаланган файдалы казылмалар запасларының сәнәгать әһәмияте турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе аларны дәүләт исәбенә алу өчен нигез булып тора.

Дәүләт экспертизасы ятманы геологик өйрәнүнең теләсә кайсы стадиясендә уздырылырга мөмкин, әмма бу чакта дәүләт экспертизасына тапшырылучы геологик

материаллар файдалы казылмалар запасларының күләмен һәм сыйфатын, халык хуҗалыгындагы әһәмиятен, аларны чыгаруның тауга бәйле техник шартларын, гидрогеологик, экологик һәм башка шартларын объектив бәяләү мөмкинлеген бирергә тиеш.

Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүгә бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат та дәүләт экспертизасы узарга тиеш. Җир асты байлыкларының мондый кишәрлекләрен файдалануга бирү геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә.

Файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

8) 86 статьяда:

а) беренче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү (эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгарудан тыш) һәм җир асты байлыкларыннан файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалану расланган техник проектлар нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көчләренә керүнең әлеге статья белән башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты һәм 6 пунктның “а” пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 2 июле
№ 50-ТРЗ